| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
| --- | --- |
| **Исполнительный комитет поселка городского типа Уруссу Ютазинского муниципального района** | **Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитеты** |
| 423950, п.г.т. Уруссу<br>ул. Пушкина, 38<br>тел. 2-61-50<br>2-92-40 | 423950, Урыссу шәһәр тибындагы поселогы<br>Пушкин урамы, 38<br>тел. 2-61-50<br>2-92-40 |


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ __22___ «_25__» __07____ 2017г.

Ютазы муниципаль районы Урыссу штп
гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге
автомобиль юлларына идентификация номерлары
бирү Тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 октябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының 2007 елның 07 февралендәге 16 номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу ш.т.п. Башкарма комитеты карар бирә:

1. Ютазы муниципаль районының Урыссу ш.т.п. гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына идентификация номерларын бирү Тәртибен 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Ютазы муниципаль районының Урыссу ш.т.п. гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына 2 нче кушымта нигезендә идентификация номерларын бирергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Ютазы муниципаль районы сайтында http://jutaza.tatarstan.ru «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазифаларын башкаручы З.Н. Айтыкина

1 нче кушымта
Ютазы муниципаль районы
Урыссу ш.т.п. Башкарма
комитетының 25" ___07____ 2017
ел №_22_ карарына

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу ш.т.п. гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына идентификация номерлары бирү**

**Тәртибе**

Автомобиль юлының идентификация номеры дүрт разрядтан тора. Автомобиль юлының идентификация номерының һәр разряды элеккесеннән буш урын калдырып аерыла.

Автомобиль юлының идентификация номеры рус алфавитының баш хәрефләреннән һәм (яисә) гарәп саннарыннан тора. Автомобиль юлының идентификация номерының бер разрядында предметлы хәреф һәм (яисә) цифр билгесе дефис белән аерылырга мөмкин.

Автомобиль юлының бер разрядында цифрлы яки хәрефле билгеләнешнең предметы автомобиль юлының идентификация номерының яисә автомобиль юлы турында башка мәгълүматларның тәңгәлләштерелгән классификация билгесенең мөстәкыйльлеге белән билгеләнә.

Автомобиль юлының идентификация номерының беренче разряды автомобиль юлын милеккә карата идентификацияли һәм өч төркемгә берләшкән сигез билгене үз эченә ала - беренче төркем ике билгедән тора; икенче һәм өченче төркем һәрберсе өч билгедән тора:

Муниципаль берәмлек милкенә караган автомобиль юлы өчен, автомобиль юлының идентификация номерының беренче разряды административ бүленеш объектларының гомумроссия классификаторы классификациясенең беренче, икенче һәм өченче дәрәҗәдәге объектлары кодларына туры килә торган өч төркемнән тора.

Автомобиль юлының идентификация номерының икенче разряды рөхсәт ителгән файдалану төрләре буенча автомобиль юлын идентификацияли һәм ике хәрефтән тора:

ОП - гомуми файдаланудагы автомобиль юлы өчен.

Автомобиль юлының идентификация номерының өченче разряды автомобиль юлын мәгънәсе буенча идентификацияли һәм ике хәрефтән тора:

МП - муниципаль берәмлек милкенә караган автомобиль юлы өчен (җирлекнең автомобиль юлы).

МГ - муниципаль берәмлек милкенә караган автомобиль юлы өчен (шәһәр автомобиль юлы).

Автомобиль юлының идентификация номерының дүртенче разряды автомобиль юлының гамәлгә кую номерыннан гыйбарәт, ул үз эченә керә торган гарәп цифрларыннан, автомобиль юлының тәртип номерыннан тора.